| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

9.01.2017 № 17-01

Казан ш.

Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкару) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүнең типовой формасын раслау турында

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 49 статьясы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкару) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүнең типовой формасын (алга таба – Типовой форма, килешү) (кушымта итеп бирелә) расларга.

2.Килешүләрнең, 2017 елга килешүләрдән башлап, Типовой форма нигезендә формалаштырылуын билгеләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
«9» январь  2017 ел №17-01
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкару) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүнең типовой формасы**

г. ________________________________________________________________
*(килешүне төзү урыны)*

«__» ________________ 20__ ел                    № ____________________________
*(килешүне төзү датасы)*                                                  *(килешү номеры)*

____________________________________________________________________________,
*(Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә карата гамәлгә куючы функцияләрен хәл итүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы (дәүләт органы) атамасы)*

үзенә, Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын алучы буларак, Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениеләренә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкару) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән, алга таба  - “Гамәлгә куючы” дип атала,
_____________________________________

____________________________________________________________________________
*(Гамәлгә куючы җитәкчесенең яки вәкаләтле затының вазыйфасы атамасы)*

_____________________________________________________ йөзендә, эш итә
*(Гамәлгә куючы җитәкчесенең яки вәкаләтле затының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)*

нигезендә ____________________________________________________________,
*(Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органы (дәүләт органы) турында нигезләмә,ышанычнамә, боерык яки вәкаләтләрне раслаучы башка документ)*

бер яктан һәм_____________________________________________________________,
*(Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесе атамасы)*

Алга таба -”Учреждение” дип атала, ____________________________________
*(Учреждение җитәкчесе яки вәкаләтле заты вазыйфасы атамасы)*

____________________________________________________________йөзендә, эш итә
*(Учреждение җитәкчесенең яки вәкаләтле затының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)*

нигезендә_____________________________________________________________,
*(Учреждение уставы яки вәкаләт биргән башка документ)*

икенче яктан, алга таба - “Яклар”дип атала, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.12.2015 ел, № 1044 карары белән расланган Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә (эшләр башкару) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) туры китереп, бу Килешүне төзеде.

I. Килешү предметы

1.1. Бу Килешүнең предметы булып Учреждениегә 20__ елда № ________ «__» _________ 20__ елга дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә (эшләр башкару) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидия (алга таба - Субсидия, дәүләт йөкләмәсе) бирү тора.

II. Субсидия бирү тәртибе, шартлары һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү

2.1. Субсидия Учреждениегә дәүләт йөкләмәсендә билгеләнгән дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкару) субсидия бирә.

2.2. Субсидия Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнарының классификациясе кодлары (алга таба – БК кодлары) буенча, Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын алучы буларак, Гамәлгә куючыга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, түбәндәге күләмдә бирелә:

БК коды буенча ________ ________ (______________________________) сум;
*(БК коды)* *(суммасы сүзләр белән)*
БК коды буенча ________ ________ (____________________________) сум;
*(БК коды)* *(суммасы сүзләр белән)*
БК коды буенча ________ ________ (___________________________) сум.
*(БК коды)* *(суммасы сүзләр белән)*

2.3.Субсидия күләме, чыгымнарның база нормативларын һәм чыгымнарның база нормативларына төзәтмә коэффициентларны һәм Нигезләмәгә туры китереп билгеләнгән эшләр башкаруга норматив чыгымнарны кулланып, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә, дәүләт йөкләмәсе күрсәткечләре буенча, исәпләнелә.

III. Субсидия күчерү тәртибе

3.1. Субсидия күчерү, Нигезләмәгә туры китереп, Учреждениегә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган лицевой счетына хәл ителә.

IV.Якларның берлектә эшләве

4.1. Гамәлгә куючы үзенә йөкли:

4.1.1. бу Килешүнең II бүлеге нигезендә Субсидия бирүне тәэмин итүне;

4.1.2. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына бу Килешүнең 2.2 пунктында күрсәтелгән Субсидия күләмен исәпләүгә нигез итеп алынган норматив чыгымнар һәм тармакның төзәтмә коэффициентлары күрсәткечләре турында мәгълүматларны норматив чыгымнар расланганнан соң (аларга үзгәрешләр кертелгәннән соң) ___ эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштыруны тәэмин итүне;

4.1.3. бу Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган, бу Килешүгә кушымта нигезендә Субсидия күчерү графигына туры китереп, бу Килешүнең VIII бүлегендә күрсәтелгән счетка Субсидия күчерүне тәэмин итүне;

4.1.4. Учреждениенең дәүләт йөкләмәсендә күздә тотылган тәртиптә дәүләт йөкләмәсен үтәвенә һәм Учреждениенең Нигезләмәдә һәм бу Килешүдә билгеләнгән шартларны үтәвенә контрольлек итүне;

4.1.5. Учреждениенең бу Килешүне үтәүгә бәйле тәкъдимнәрен карап тикшерүгә, шул исәптән Субсидия күләмен үзгәртү буенча, һәм Учреждениегә, тәкъдимнәр алынганнан соң ___ эш көненнән дә соңга калмыйча, аларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карарлар җибәрүгә;

4.1.6. дәүләт йөкләмәсендә билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтү күләме хисап чоры йомгаклары буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең факттагы күләменнән тайпылган очракта, дәүләт йөкләмәсендә билгеләнгән дәүләт хезмәтләре күләмен билгеләүче күрсәткечләргә үзгәрешләр кертүне;

4.1.7.Учреждение тарафыннан Гамәлгә куючыга 20__ елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарырга тиешле Субсидия средстволарын Татарстан Республикасы бюджетына күчерүне тәэмин иткән чаралар күрүне;

4.1.8. Россия Федерациясе бюджет законында, Нигезләмәдә һәм бу Килешүдә күздә тотылган башка йөкләмәләрне үтәүне[1]:

4.1.8.1. ______________________________________________________________;

4.1.8.2. ______________________________________________________________.

4.2. Гамәлгә куючы хокуклы:

4.2.1. Учреждениедән Учреждениенең дәүләт йөкләмәсен үтәвенә контрольлек итү өчен кирәкле мәгълүматлар һәм документлар соратып алуга;

4.2.2. Субсидия күләмен үзгәртү турында карар кабул итүгә:

4.2.2.1. түбәндәге очракларда, дәүләт йөкләмәсендә билгеләнгән дәүләт хезмәтләре күрсәтү (эшләр) күләмен билгеләүче күрсәткечләрне тиешенчә үзгәрткәндә:

4.2.2.1.1. Гамәлгә куючыга бу Килешүнең 2.2 пунктында күрсәтелгән, элек расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары киметелгәндә;

4.2.2.1.2. дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә ихтыяҗ артканда (Гамәлгә куючының бюджет йөкләмәләре лимитлары булганда) яки дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) ихтыяҗ кимегәндә;

4.2.2.1.3. бу Килешүнең 4.4.2 пункты нигезендә җибәрелгән Учреждение тәкъдимнәрен карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул ителгәндә;

4.2.2.2. Учреждение хезмәткәрләренә (хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә) дәүләт хезмәте күрсәтү (эш башкару) белән турыдан-туры бәйле түләү күләмнәрен, дәүләт

---

1 Башка конкрет хәлләр күрсәтелә (булганда).

хезмәте күрсәтүгә (эш башкару) бәйле булып,  Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары кабул ителү (Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларына үзгәрешләр кертелү) сәбәпле дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү күләмен үзгәртүгә китергән дәүләт хезмәте күрсәтү (эш башкару) белән бәйле башка түләүләрне үзгәртүгә бәйле рәвештә норматив чыгымнарга үзгәрешләр кертелгән очракта дәүләт йөкләмәсендә билгеләнгән дәүләт хезмәтләре күрсәтү (эшләр) күләмен билгеләүче күрсәткечләрне тиешенчә үзгәртмичә;

4.2.3. Россия Федерациясе бюджет законында, Нигезләмәдә һәм бу Килешүдә күздә тотылган башка хокукларны тормышка ашыруга[2]:

4.2.3.1. ____________________________________________________________;

4.2.3.2. ____________________________________________________________.

4.3. Учреждение үзенә йөкли:

4.3.1. Гамәлгә куючының запросы буенча ___ көн эчендә бу Килешүнең 4.1.4. пунктында күздә тотылган контрольлекне хәл итү өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны тапшыруны;

4.3.2.«__» ___________ 20__ елга[3] кадәр 20__ елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарырга тиешле Субсидияләр средстволарын кире кайтаруны;

4.3.3. Субсидияләр средстволарын, ______________________________________________________________[4]

*(Гамәлгә куючының норматив-хокукый актлары реквизитлары)*

Нигезендә билгеләнгән тәртиптә эшләнеп расланган Учреждениенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында (алга таба – финанс-хуҗалык эшчәнлеге планы) билгеләнгән түләүләргә җибәрүне;

4.3.4. Гамәлгә куючыга Нигезләмәгә туры китереп тапшыруны:

4.3.4.1. дәүләт йөкләмәсендә билгеләнгән срокта һәм ешлыкта, Нигезләмәгә №2 кушымта нигезендәге форма буенча, дәүләт йөкләмәсен үтәү турында хисапны;

4.3.5. Россия Федерациясе бюджет законында, Нигезләмәдә һәм бу Килешүдә билгеләнгән башка бурычларны үтәүне[5]:

4.3.5.1. ____________________________________________________________;

4.3.5.2. ____________________________________________________________.

4.4. Учреждение хокуклы:

4.4.1. бу Килешүнең 4.3.2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле Субсидия средстволарыннан тыш, Учреждение уставында күздә тотылган максатларга ирешү өчен, финанс-хуҗалык эшчәнлеге планына туры китереп, 20__ елда[6] файдаланылмый калган Субсидия калдыгын 20__ елдагы[7] чыгымнарны хәл кылуга

2 Башка конкрет хокуклар күрсәтелә (булганда).

3 Числосы һәм ае, шулай ук Субсидия бирү елыннан соң килүче, әмма Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән сроклардан да соңга калмаган ел күрсәтелә.

4 Учреждениенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау тәртибен билгеләгән Гамәлгә куючының хокукый акты реквизитлары күрсәтелә

5 Башка конкрет бурычлар күрсәтелә (булганда).

6 Субсидия бирү елы күрсәтелә.

7 Субсидия бирү елыннан соң килүче ел күрсәтелә.

җибәрүгә;

4.4.2. Гамәлгә куючыга бу Килешүне үтәү буенча тәкъдимнәр, шул исәптән Субсидия күләмен үзгәртү буенча, җибәрүгә;

4.4.3. Гамәлгә куючыга, бу Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә аңлатмалар алу максатында, мөрәҗәгать итүгә;

4.4.4. Россия Федерациясе бюджет законында, Нигезләмәдә һәм бу Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны тормышка ашыруга[8]:

4.4.4.1. ______________________________________________________________;

4.4.4.2. ______________________________________________________________.

## V. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар, бу Килешү буенча бурычларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

5.2. Бу Килешү буенча Якларның үз бурычларын үтәмәвенә яки тиешенчә үтәмәвенә җаваплылыгы турында башка нигезләмәләр[9]:

5.2.1. ________________________________________________________________;

5.2.2. ________________________________________________________________.

## VI. Башка шартлар

6.1. Бу Килешү буенча башка шартлар[10]:

6.1.1. ________________________________________________________________;

6.1.2. ________________________________________________________________.

## VII. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Килешүне өзү якларның үзара ризалыгы буенча хәл ителә һәм бу Килешүне өзү турында килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

7.2. Анда билгеләнгән нигезләр буенча дәүләт йөкләмәсен үтәү вакытыннан алда туктатылганда, күрсәтелми калган дәүләт хезмәтләре (башкарылмый калган эшләр) күләмен билгеләүче күрсәткечләргә туры килгән күләмдә, файдаланылмый калган Субсидия калдыклары Учреждение тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

7.3. Бу Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә Яклар арасында килеп туган бәхәсләр алар тарафыннан, мөмкинлеккә карап, тиешле беркетмәләр яки башка документлар рәсмиләштерү нигезендә, сөйләшүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Үзара ризалыкка ирешелмәгәндә, Яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

7.4. Бу Килешү Якларның һәркайсы исеменнән эш итү хокукына ия булган затлар тарафыннан имзаланганнан соң үз көченә керә, әмма бу Килешүнең 2.2 пунктында күздә тотылган бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгәч кенә, һәм Якларның бу Килешү буенча үз бурычларын тулысынча үтәвенә кадәр гамәлдә була.

7.5. Бу Килешүне үзгәртү, шул исәптән бу Килешүнең 4.2.2 пункты нигезләмәләре буенча, Якларның үзара ризалыгы белән хәл ителә һәм бу Килешүнең аерылгысыз өлеше

---

8 Башка конкрет хокуклар күрсәтелә (булганда).

9 Башка конкрет нигезләмәләр күрсәтелә (булганда).

10 Бу Типовой формада билгеләнгән шартлардан тыш, башка конкрет шартлар күрсәтелә (булганда).

булып торган өстәмә килешү рәвешендә рәмиләштерелә.

7.6. Бу Килешү ике нөсхәдә, һәр ике як өчен дә берәр нөсхәдә, кәгазь бокумент рәвешендә төзелде.

VIII. Якларның түләү өчен реквизитлары

| | |
|---|---|
| Гамәлгә куючы атамасы,<br>ОГРН, ОКТМО | Учреждение атамасы<br>ОГРН, ОКТМО |
| Урнашу урыны: | Урнашу урыны: |
| ИНН/КПП | ИНН/КПП |
| Түләү реквизитлары:<br>Түләүче атамасы,<br>Россия Банкы учреждениесе атамасы,<br>БИК,<br>Расчет счеты,<br>Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган лицевой счеты | Түләү реквизитлары:<br>Түләүче атамасы,<br>Россия Банкы учреждениесе атамасы,<br>БИК,<br>Корреспондент счеты,<br>Расчет счеты,<br>Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган лицевой счеты |

IX. Якларның имзалары

| Гамәлгә куючының кыскартылган атамасы | Учреждениенең кыскартылган атамасы |
|---|---|
| _______________/ _______________<br>(имза) (ФИО) | _______________/ _______________<br>(имза) (ФИО) |

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
« 9 » январь 2017 ел № 17-01
боерыгы белән расланган
Татарстан Республикасы дәүләт
бюджет яки автоном учреждениесенә
дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкару)
дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс
ягыннан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы
бюджетыннан субсидияләр бирү турында
килешүнең типовой формасына кушымта

____________ № _____
Килешүгә
№ ___кушымта

Субсидия күчерү графигы

Гамәлгә куючы атамасы ________________________________________________________
Учреждение атамасы ________________________________________________________

| № п/п | Россия Федерациясе бюджет классификациясе коды (Субсидия бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары буенча) [i] | | | | Субсидия күчерү сроклары[ii] | Күчерелергә тиешле сумма, сумнарда |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | кисәге коды | бүлеге, бүлекчәсе | максатчан статьясы | чыгымнар төре | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1 | | | | | - «__» ________ 20__ ел.кад. | |
| 2 | | | | | «__» ________ 20__ ел.кад. | |
| 3 | | | | | «__» ________ 20__ ел.кад. | |
| КБК буенча барлыгы | | | | | х | |
| | | | | | «__»________ 20__ ел.кад. | |
| | | | | | «__» ________ 20__ ел.кад. | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | «__» ________ 20__ ел.кад. | |
| | | | | | | |
| КБК буенча барлыгы | | | | | х | |
| | | | | | Җәмгысе: | |

---

i Килешүнең 2.2 пункты нигезендә күрсәтелә

ii Учреждениегә Субсидия күчерүнең конкрет сроклары күрсәтелә